ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУРАКАЙ АВЫЛЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423746, Чуракай авылы, Совет ур., 69нчы йорт. Тел.:(85552)3 44 65;
E-mail: chrk.akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУРАКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423746, село Чуракаево, ул. Советская, дом 69. Тел.:(85552)3 44 65
E-mail: chrk.akt @yandex.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«27» январь 2026 ел № 6

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Чуракай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге буенча җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24 һәм 28 статьяларына, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Актаныш муниципаль районының Чуракай авыл җирлеге Уставына туры китереп, Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Чуракай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге буенча җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлауларын 2026 елның 03 февраленә билгеләргә.
2. Ачык тыңлаулар үткәрү урыны итеп: Чуракай мәдәният йорты бинасын билгеләргә, Чуракай авылы, Совет урамы, 69 нчы йорт адресы буенча көндезге 13:00 сәгатьтә; Иске Эгбэз авылы клуб бинасын билгелэргэ, Иске Эгъбэз авылы, Ленин урамы, 53енче йорт адресы буенча кондезге 14.00 сэгаттэ уткэрергэ.
3. Җәмәгать тыңлауларында каралачак мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм фикерләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Чуракай авылы, Совет урамы, 69 нчы йорт.
4. Бу карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат такталарында, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча “Авыл җирлеге” бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.
5. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Чуракай авыл җирлеге**
Башкарма комитеты җитәкчесе Хайдаров Р.Р.